19. Motigullina, A. R., Gaynullina, G. R. (2016). *A. Yakhin kak yarkii predstavitel' nauchnoi shkoly sistemno-kompleksnogo izucheniya literatury i iskusstva Kazanskogo universiteta* [A. Yakhin as a Prominent Representative of the Kazan University Scientific School of the System-Comprehensive Research into Literature and Art]. Philology and Culture. No. 4 (46), pp. 314–324. (In Russian)

20. Kharrasova, R. F. (2023). *Ibrahim Zinnat uly Nurullin – galim, tankyit'che ham prozaik* [Ibragim Nurullin as a Scientist, Critic and Prose Writer]. Tatarica. No. 20 (1), pp. 182–188. (In Tatar)

21. Yusupova, N. M., Gaynullina, G. R. (2022). *Zhizn', posvyashchennaya nauke (K 90-letiyu so dnya rozhdeniya professora kazanskogo universiteta R.K. Ganievoi)* [A Life Dedicated to Science (On the 90th anniversary of Kazan University Professor R. Ganieva)]. Philology and Culture. No. 3 (69), pp. 316–321. (In Russian)

22. Sayfulina, F. S. (2022). *Kurenekle adabiyat galime Azat Gyil'mulla uly Akhmadullin* [Outstanding Literary Scholar Azat Gilmullinovich Akhmadullin]. Tatarica. No. 2(19), pp. 173–181. (In Tatar)

23. Ylmaz, G. M., Zavgarova, F. Kh., Khabutdinova, M. M. (2023). *Tvorcheskii portret fol'klorista Marselya Bakirova v zerkale ego lichnykh vospominanii i v otsenke sovremennikov* [Folklorist

Marcel Bakirov's Creative Portrait in the Mirror of His Personal Memories and in the Assessment of His Contemporaries]. Tatarica. No. 2 (21), pp. 42–58. (In Russian)

24. Khabutdinova, M. M., Yusupova, N. M. (2020). *Literaturno-kriticheskaya i nauchnaya deyatel'nost' T. Sh. Gilazova* [T. Gilazov's Literary-Critical and Scientific Activity]. Philology and Culture. No. 4 (62), pp. 187–190. (In Russian)

25. Yusupov, A. F. (2021). *Al'bert Gatuf uly Yakhinnyn fanni-metodik eshchanlege* [Scientific and Methodological Work of Albert Yakhin]. TATARICA. No. 17 (1), pp. 166–171. (In Tatar)

---

# КАЗАН УНИВЕРСИТЕТЫНДА ТАТАР ӘДӘБИЯТ БЕЛЕМЕ: ТАРИХЫ ҺӘМ БҮГЕНГЕСЕ

**Нурфия Марс кызы Юсупова,**
Казан федераль университеты,
Россия, 420008, Казан ш., Кремль ур., 18 нче йорт,
faikovich@mail.ru.

Мәкалә Казан университетында татар әдәбият белеменең үсешен өйрәнүне алга куя, уку йортында эшләгән галимнәрнең фәнни эшчәнлегенә күзәтү аша әлеге процессның төп аспектларын, гыйльми юнәлешләрен аерып чыгара, шушы юлда уку йортының, анда эшләгән галимнәрнең татар әдәбият белеменә керткән өлешен, урынын тәгаенләштерә.

Казан университетында татар әдәбияты, уку-укыту программаларына кертелеп, предмет буларак, 1944 елда укытыла башлый, татар теле һәм әдәбияты кафедрасының оешуы татар әдәбияты буенча әйдәп баручы белгечләрнең шушы мәйданга тупланауына зур йогынты ясый. Бу күренеш, үз чиратында, университетта татар әдәбият белеме өлкәсендәге гыйльми эзләнүләрнең фәнни-филологик (татар әдәбиятын, тәнкыйди фикер үсешен төрле яссылыкларда өйрәнү) һәм методик (югары уку йортлары студентлары, соңрак урта мәктәп укучылары өчен лекцияләр курсы, программалар, дәреслекләр, методик кулланмалар эшләү) аспектларда формалашуын һәм тармакланып үсүен тәэмин итә. Әлеге мәкалә шушы процессны төп өйрәнү объекты итеп куя, архив документларына таянып, фәнни хезмәтләргә, әйдәп баручы мөгаллимнәрнең методик һәм педагогик эшчәнлегенә бәя аша раслый, аның яңалыгы һәм актуальлеге шуның белән билгеләнә.

Мәкалә чикләрендәге эзләнүләрнең төп максаты – Казан университетында татар әдәбият белеменең үсешен, әлеге процессның төп аспектларын, гыйльми нигезләрен билгеләү. Бу процесс уку йортында оешкан татар теле һәм әдәбияты, соңрак татар әдәбияты кафедрасының эшчәнлеге белән янәшә, шушы структур берәмлек эчендә алып барыла. Шуңа мөнәсәбәттә әлеге язмада татар әдәбияты кафедрасының үсеш-үзгәреш тарихына да бөтенлекле күзәтү ясала.

**Төп төшенчәләр**: Казан университеты, татар әдәбияты, әдәбият белеме, фәнни эшчәнлек, татар әдәбияты кафедрасы

## Кереш

Казан университеты – дөньякүләм танылган уку йорты, белем учагы гына түгел, тарихының буеннан-буена ориенталистик, тюркологик тикшеренүләрне күз уңында тоткан көчле, фәнни куәскә ия гыйльми үзәкләрнең берсе дә. Татар теле ориенталистика кысаларында 1812 елда ук уку программаларында урын ала, табигый төстә тюркологик тикшеренүләр юлындагы тәүге адымнар да шул вакытта ук ясала. Казан университетында татар әдәбият белеменә бәйле тәүге эзләнүләр Н.Ф. Катанов исеме белән бәйләнгән: 1894 елда ул, татар телен укытуны тергезү белән беррәттән, әдәбият белеме буенча да аерым эзләнүләрне башлап җибәрә, кулъязмаларны җыю, тикшерү эшен дәвам итә. 1924-25 уку елыннан Казан университетының эшчеләр факультетында укучы татар студентлары өчен, татар теле белән беррәттән, татар әдәбияты мәҗбүри предмет буларак укытыла башлый. 1930 елдан биредә укучы барлык студентларга да татар әдәбиятыннан дәресләр бирелә, әмма 1933 елда туктатыла.

Татар әдәбиятын укыту кабат 1944 елда – татар теле һәм әдәбияты кафедрасы оешкан

чорда – тергезелә һәм әдәбият белеменә бәйле тулы канлы эзләнүләр дә шушы дәвердән башланып китә. Шуңа да Казан университетында татар әдәбият белеменә бәйле тикшеренүләрнең 80 еллык тарихы бар дип исәпләнә. Уку йортында татар әдәбият белеме өлкәсендәге фәнни эзләнүләр һәм татар әдәбияты кафедрасы үсеше бер-берсе белән тыгыз бәйләнгән, алар бербөтен.

1920 елларда ил күләмендә фольклор җыюның, фольклористик һәм, гомумән, филологик тикшеренүләрнең иҗтимагый әһәмияте көчәя. Ул, асылда, стихияле рәвештә барлыкка килеп, үз чорында киң таралыш алган инкыйлабка һәм гражданнар сугышына бәйле халык авыз иҗаты үрнәкләрен саклауның кирәклеге һәм фәнни әйләнешкә кертеп җибәрүнең мөһимлеге белән аңлатыла. 1940–1943 елларда татарларда да үз тамырлары, халык авыз иҗаты үрнәкләре белән кызыксыну көчәя, ул «халыкны патриотик тәрбияләүнең нигез чарасы итеп күрелә башлый» [1, б. 102].

Әлеге үзгәрешләрнең матур бер дәвамы төсендә, 1944 елның 24 апрелендә СССР Халык Комиссарлары Советы каршындагы Югары мәктәп эшләре буенча Бөтенсоюз комитетының рәис урынбасары П. Золотухинның 1944 елның 1 июненнән В.И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университетында татар теле һәм әдәбияты кафедрасы ачылу турындагы приказы чыга һәм аңа 4 штат бирелә. Университет тарихында яңа структур берәмлекнең һәм фәнни юнәлешнең ачылуына уку йортындагы фәнни атмосфера да зур йогынты ясый [2, б. 212]. Аның беренче мөдире итеп СССР Фәннәр академиясенең Тел, СССР халыкларының язма мирасын өйрәнү институтында аспирантура тәмамлап, 1944 елның 30 июнендә Мәскәүдә атаклы галим, филолог, тарихчы, этнограф һәм археолог Н. Марр җитәкчелегендә «Глагольное управление в современном литературном языке» темасына кандидатлык диссертациясен яклаган һәм филология фәннәре кандидаты дәрәҗәсен алган Рәбига Афзал кызы Хәкимова билгеләнә.

Казан университетында татар әдәбият белеменең, гомумән, филология юнәлешенең үсеше, татар әдәбияты кафедрасының аерым чорлардагы эшчәнлеге Р.Р. Җамалетдинов һәм М.М. Хәбетдинова [1], Х.Й. Миңнегулов [3], Д.Г. Тумашева [2], И.И. Ханипова [4], И.Э. Ярмәкәев, Р.Ф. Мөхәммәтшина [5] һ.б. галимнәрнең мәкаләләрендә өйрәнү объекты итеп күтәрелә. Моннан тыш, университетның 2004 елгы юбилее уңаеннан биредә гыйльми тикшеренүләр үсешенә, яшь буынны тәрбияләүгә мөһим өлеш керткән галимнәргә бәйле ярдәмлек-кулланмалар эшләнә. Х.Г. Госман [6], Н.Г. Юзиев [7], Ш.Ә. Садретдинов [8], М.С. Мәһдиев [9] кебек шәхесләргә атап язылган әлеге кулланмаларда да татар әдәбият белеменең үсеше аерым галимнәр эшчәнлегенә мөнәсәбәтле яктыртыла. Татар факультетының төрле еллардагы юбилейларына атап эшләнгән китапларда да татар әдәбият белеменең үсешенә бәйле аерым фикерләр урын ала [10; 11; 12].

## Хезмәтнең методологик нигезе

Әлеге мәкаләдә Казан университетында татар әдәбият белеменең диахроник һәм синхроник аспектларда үсешен өйрәнү, шушы юлда татар әдәбияты кафедрасының эшчәнлеген тасвирлау, тоткан урынын билгеләү, бу өлкәдә хезмәт куйган галимнәрнең фәнни-методик мирасын барлау бурычы куела.

Мәкаләне язу барышында, төп методлар буларак, тасвирлама, тарихи-чагыштырма һәм аксиологик методлар үзәккә куелды. Тасвирлама метод Казан университеты галим-мөгаллимнәренең фәнни һәм педагогик-методик эшчәнлеген өйрәнү юлында файдаланылды. Тарихи-чагыштырма һәм аксиологик методлар уку йорты белән бәйле татар әдәбият белеменең үсеш-үзгәреш тарихын өйрәнү барышында кулланылды.

## Фикер алышу

Татар теле һәм әдәбияты кафедрасы оешу Казан университетында татар әдәбият белеме өлкәсендәге фәнни эзләнүләрнең көчәюенә зур этәргеч ясый. Бу юлдагы тәүге адымнар татар әдәбиятыннан югары белемнең әдәби барышны бөтенлекле системага салып, концептуаль нигездә өйрәнелергә тиешлеген көн тәртибенә куюдан башланып китә. Шуны күздә тотып, оешкан вакытта ук «кафедра әгъзалары татар әдәбияты тарихы курсын эшләү»нең [4, б. 231-232] мөһимлеген күтәреп чыга. Табигый ки, бу юнәлештәге фәнни эзләнүләр диахроник аспектта үсеп китә: 1950-1951 уку елына татар теле һәм әдәбияты кафедрасы әгъзалары тарафыннан татар халык авыз иҗаты, XIX гасыр татар әдәбияты, Совет әдәбияты, әдәбият укыту методикасы буенча уку-укыту программалары, лекцияләр курсы эшләнеп җитә [13, б. 1-51; 14, б. 145]. Әмма аерым чорларны, аеруча урта гасырлар әдәбиятын укыту өчен белгечләр булмавы программалар эшләү барышында ук үзен нык сиздерә.

Х.Г. Госман истәлекләреннән күренгәнчә, ул вакытта сүз сәнгатенең тирән катламнарына, ерак тарихи сәхифәләренә бәйле фәнни материал аерым әдипләр турындагы өзек-өзек мәгълүматлардан гына оештырыла [1, б. 106]. Татар халык авыз иҗаты башта ук аерым предмет буларак аерып куела, әмма аның буенча программалар төзү барышында, шул чор идеологиясенә аваздаш төстә, инкыйлабка кадәрге фабрика һәм завод эшчеләренең халык авыз иҗаты үрнәкләре, эшчеләр язмышына бәйле хикәятләр, такмаклар, җырлар алга чыгарыла, әлеге фольклор жанрларын анализлауга, өйрәнүгә басым ясала. Болардан тыш, шул чор тормышына, җимерекләрне торгызуга бәйле яисә халык дошманнары, сугыш вакыйгалары белән көрәш дулкынында язылган такмаклар, халык җырлары тупланып, аларны өйрәнүнең эзлекле системасы юнәлешендә эш башланып китә [14, б. 5-6].

Әдәбият тарихын, бигрәк тә урта гасырлар сүз сәнгате үсешен өйрәнү һәрдаим әдәби ядкярләрне татар укучысына кайтару эше белән янәшә алып барыла, мондый белгечләрнең бер көндә генә әзерләнмәвен күздә тотып, беренче көннәреннән үк кафедра бу юнәлештә дә эшне башлап җибәрә. Уку-укыту эшен җайга салуда, программалар эшләүдә укытучы-мөгаллимнәргә Казан Тел, әдәбият һәм тарих институты (КТӘТИ) галимнәре Я.Х. Агишев, М.Х. Гайнуллин, Х.Х. Ярми, Г.М. Халитләр дә ярдәмгә килә.

1951 елдан татар теле һәм әдәбияты кафедрасы мөдире итеп әдәбиятчы галим, шигырь теориясе белгече Хатип Госман билгеләнә, Казан университетында татар әдәбият белеменең үсеше һәм тармаклануы нәкъ менә аның исеме белән бәйләнеп китә. Татар филологиясе буенча университетта эшләрлек белгечләр булмауны күздә тотып, ул башта ук чыгарылыш курс студентларын башка уку йортларына, фәнни оешмаларга аспирантурага җибәрү эшен җайга сала. 1951 елдан кафедрада укытучылар саны 5кә җиткерелә, аларга 1 лаборант билгеләнеп, 4 аспирант алына. Кафедрага әдәбиятчы Я. Агишевның килүе дә әдәбият белемендәге эзләнүләрне киңәйтү һәм тирәнәйтү мөмкинлеген бирә. 1955 елдан 1959 елга кадәр кафедрага татар әдәбияты юнәлеше буенча И.З. Нуруллин, З.М. Мәҗитов, М.Х. Хәсәнов, Н.Г. Юзиев эшкә алына, Ж.Д. Алмазов һәм А.Г. Яхин аерым сәгатьләр укыту өчен чакырыла [15, б. 9-20].

Кафедрада әдәбият белеме өлкәсендә әйдәп баручы яшь белгечләрнең туплануы 1950 елларның уртасыннан әдәби-нәзари эзләнүләрнең синхроник аспектта алып барыла башлавына да зур этәргеч бирә: әдәби барышта иҗат юнәлешләре һәм агымнары, аерым алганда, тәнкыйди реализм һәм социалистик реализм иҗат методлары өйрәнелеп, студентларга махсус курс форматында укытыла башлый [16, б. 8].

1950 елларда мәктәпләр өчен язылган дәреслекләргә ревизия башлану әдәбият кафедрасында эшчәнлек мәйданнарының киңәюенә китерә. Ревизия нәтиҗәсендә дәреслекләрдә инкыйлабка кадәрге әдәбиятны яңадан язу кирәклеге көн тәртибенә куела һәм бу эш тә университетның татар теле һәм әдәбияты кафедрасына, аерым алганда, Х.Г. Госман һәм Я.Х. Агишевка йөкләнә. Шушы чордан башлап, университетның татар теле һәм әдәбияты кафедрасында методик эзләнүләр, мәктәпләр өчен программа-дәреслекләр язу эше башланып китә. Ә бу үзеннән-үзе кадрлар үстерү, яңа гыйльми көчләр әзерләү мәсьәләсен көн тәртибенә куя. Шул рәвешле кафедрада татар әдәбияты аерым юнәлеш булып формалашып өлгерә, укытучылар составы туплана, мөстәкыйль берәмлек буларак аерылып чыгу өчен тулы җирлек әзерләнеп җитә.

1960 елда татар әдәбияты кафедрасы мөстәкыйль берәмлек буларак аерылып чыга, һәм алга таба аның төп үсеш перспективалары билгеләнә: 1) кадрлар мәсьәләсен хәл итү, актив төстә талантлы яшьләр арасыннан кадрлар әзерләүне активлаштыру (моның өчен башка югары уку йортларындагы әзерлек курсларында укып кайту да күздә тотыла); 2) текстологик эш: әдәби ядкярләрне табып, төрле илләрнең архивларыннан кайтартып, бастырып чыгару һәм киң фәнни әйләнешкә кертеп җибәрү, аларны университетта әдәбият укыту барышында иркен файдалану; 3) татар әдәбияты буенча югары уку йортлары өчен көн таләбенә җавап биргән дәреслекләр язу; 4) студентлар белән берлектә фольклор экспедицияләрен оештыру; 5) татар әдәбиятын бөтенлекле, эзлекле процесс буларак өйрәнүнең фәнни концепциясен булдыру һәм шушы нигездә әдәбият тарихын эшләп чыгу; 6) студентларның фәнни эшчәнлеген җайга салу, шул юлда киләчәк өчен фәнни потенциал әзерләү. Аерым мөстәкыйль берәмлек булып аерылып чykканнан башлап, 1989 елга кадәр Казан университетының татар әдәбияты

кафедрасы Х.Г. Госман (1952–1975), А.Г. Яхин (1975–1980), А.Г. Әхмәдуллин (1981–1999) мөдирлегендә шушы юнәлешләрне нигез итеп алып үсә-камилләшә; 1) халык авыз иҗатыннан башлап, милли әдәбиятның үсеш-үзгәреш тарихы; 2) әдәбият теориясе; 3) әдәби тәнкыйть юнәлешләре, шушы юнәлешләрдә тирән гыйльми эзләнүләр алып бару татар әдәбияты кафедрасының төп фәнни мәсләге итеп куела.

Париж, Лондон, Лейден архивларында яткан урта гасыр әдәби ядкярләренең фотокопияләре кайтартылып, кириллицага күчерелә башлый. Шушы эшчәнлекнең нәтиҗәсе буларак 1971–1979 еллар аралыгында Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф», Котбның «Хөсрәү вә Ширин», Сәйф Сараиның «Гөлстан бит-төрки» басмалары дөнья күрә. Х. Госман күрсәткәнчә, бу эшне башкарырлык яшьләр җитмәү сәбәпле, өлкән буын вәкилләре, аерым алганда, татар, рус, гарәп, фарсы телләрен яхшы белгән З.А. Максудова да эшкә тартыла [1, б. 109]. Гарәп, фарсы, төрек, үзбәк, казакъ, рус, алман һәм француз телләрен яхшы белгән, борынгы кулъязмалар буенча сирәк белгеч Җ.Д. Алмазов көче белән «Кыйссаи Йосыф», «Җөмҗөмә солтан» дастаннары укучыга кайтарыла, Г. Кандалый, Г. Сәмитова китапларының текстологиясе эшләнеп, бастырып чыгарыла. Скифларның төрки телле булуларын раслаган уникаль галим студентларга борынгы һәм урта гасырлар төрки-татар әдәбияты буенча лекцияләр укый башлый.

Кадрлар мәсьәләсе үзенең актуальлеген югалтмый, бу очракта сан гына түгел, сыйфат үзгәреше алга куела башлый: фән докторлары, фән кандидатлары әзерләү эше актуальләшә. Мәсәлән, 1962 елда Казан университеты тарихында Х.Г. Госман тарафыннан татар әдәбияты буенча беренче докторлык диссертациясе яклана (аңа кадәр М.Х. Гайнуллин докторлык диссертациясен Мәскәүдә яклап кайткан була). Татар әдәбияты кафедрасының укытучылар составына Н.Г. Юзиев, Р.К. Ганиева, Х.Й. Миңнегулов, Ш.Ә. Садретдиновлар килеп кушыла, алар кандидатлык диссертацияләрен яклап, татар әдәбият белемен үстерү юлына чыга.

Шушы чордан университеттагы һәр галим-мөгаллимнең фәнни эзләнүләре үз гыйльми юнәлеше тирәсендә тупланып үсеп китә. Мисал өчен, Х.Г. Госман һәм Н.Г. Юзиев [17, б. 172–178] татар шигырь төзелеше һәм поэтикасы юнәлешендә киң фәнни эзләнүләр алып бара, соңрак аларга килеп кушылган Х.Й. Миңнегулов, Ш.Ә. Садретдинов урта гасыр әдәбиятын, XIX гасыр сүз сәнгатен тикшерүгә, Р.К. Ганиева татар сүз сәнгатенең көнчыгыш әдәбиятлары белән бәйләнешләрен өйрәнүгә керешә, тарихчы М.А. Усманов татар чыганакчылык белемен фәнни дәрәҗәгә күтәрү белән ярдәм итә.

Милли әдәбиятның фольклордан башлап, үсеш-үзгәреш тарихын өйрәнү кафедраның төп фәнни юнәлешен хасил итә. Кафедра мөдире булган Х.Г. Госман 1920 еллар татар шигъриятен социалистик реализм белән бәйләнештә өйрәнү юлына кереп китә («Егерменче елларда татар поэзиясе», 1964), үз фәнни нәтиҗәләрен студентлар белән уртаклашып, татар әдәбияты тарихын укыта. Галим тарафыннан тәүге тапкыр төрки поэзиянең генезисы һәм үсеш-үзгәреш барышы өйрәнү объекты булып күтәрелә («Тюркский стих в средние века», 1967), төрки-татар шигыренең ритмик төзелеше формалашу хакындагы фәнни тәгълимат мәйданга чыга («Шигырь төзелеше», 1975) һәм бу эзләнүләрнең төп нәтиҗәләре университет студентларына махсус курслар буларак барып ирешә.

Р.К. Ганиева милли сүз сәнгатенең гареб, рус, фарсы, гарәп, иран-таҗик, төрки әдәбиятлар белән бәйләнешләрен өйрәнү юнәлешендә төп белгечкә әверелә, Шәрык халыклары әдәбияты буенча лекцияләр курсын эшли [18, б. 155–163]. Галимә «Восточный Ренессанс и поэт Кул Гали» (1988), «Совет көнчыгышы әдәбиятларында иҗат методы мәсьәләсе» (1988) кебек монографияләрендә һәм махсус курс программаларында көнчыгыш яңарыш фәлсәфәсенең үзәген тәшкил иткән әфлатүн фәлсәфәсен, акыл культын, гуманлылык идеалларын яки ренессанс, суфичылык мотивларын, аларның төрки сүз сәнгатьләренә килеп керү һәм әдәби үзләштерелү хасиятләрен төп өйрәнү объекты итеп күтәрә.

М.Х. Бакиров, М.С. Мәһдиев, А.Г. Яхин эзләнүләрендә халык авыз иҗатының үсеш-үзгәреш үзенчәлеген системалы тикшерү алга куела. 1975 елда Казан университеты Тарту-Мәскәү семиотик мәктәбе тикшеренүләренең бер базасы итеп билгеләнә, Й.Г. Нигъмәтуллина җитәкчелегендә сүз сәнгатен структур-семиотик тикшерүләр активлашып китә. Бу эзләнүләрне милли әдәбият материалында раслауга һәм киңәйтүгә татар әдәбияты кафедрасыннан А.Г. Яхин

билгеләнә һәм үзенең фәнни эшчәнлеген шушы нәзари тәгълиматка нигезләнеп оештыра башлый [19, б. 314–324]. Бу юлда А.Г. Яхин төп өйрәнү объекты итеп халык авыз иҗаты үрнәкләрен сайлап ала һәм аны бөтенлекле система итеп тикшереп чыга. Галимнең «Система татарского фольклора» (1984), М.Х. Бакиров белән берлектә язылган «Фольклор жанрларын система итеп тикшерү тәҗрибәсе» (1979), М.С. Мәһдиев белән бергә нәшер ителгән «Халык иҗаты әсәрләрен система итеп тикшерү тәҗрибәсе» (1982) хезмәтләре шуны раслый.

Х.Й. Миңнегулов һәм Ш.Ә. Садретдинов борынгы һәм урта гасырлар төрки-татар әдәбиятын, XIX гасыр сүз сәнгате үсешен өйрәнүне җәелдереп җибәрә. Ш.Ә. Садретдинов XIX гасыр әдәбиятын бербөтен процесс буларак тикшерү юлында үз концепциясен булдыра, шушы дәвер татар әдипләренең иҗат портретларын тудыра («Сәгыйть Рәмиев иҗаты» (1974), «XIX йөз татар әдәбияты ядкярләре» (Х.Й. Миңнегулов белән берлектә, 1982) һ.б.). Х.Й. Миңнегуловның хезмәтләрендә урта гасырның теге яки бу чоры гына аерып алып өйрәнелми, ә шушы зур этап бербөтен буларак комплексны тикшерелә. Галим төрки-татар сүз сәнгатенең урта гасыр көнчыгыш әдәбиятлары белән бәйләнешләрендәге иҗади механизмнарын таба, сүз сәнгате үсешендә фарсы, гарәп, таҗик, азәрбайҗан әдәбиятларының ролен билгели. Бу исә төрки-татар әдәбиятында нәзирәчелек күренешен эзлекле ачыкларга, бәяләргә, традицияләрне һәм яңачалыкларны ачыграк тоярга, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрендә аңлатырга мөмкинлек бирә («XIX йөз татар хрестоматияләре» (Ш.Садретдинов белән берлектә, 1982) һ.б.).

XX йөз башы – татар әдәбиятының алтын дәвере – буенча эзләнүләр И.З. Нуруллинның, соңрак М.С. Мәһдиевнең төп өйрәнү объекты булып күтәрелә. И.З. Нуруллин XX йөз башы әдәбиятының төп үсеш сукмакларын билгели [20, б. 182–188], шушы юнәлештә язылган «XX йөз башы татар әдәбияты» (1962), «Путь к зрелости» (1971), «Тормыш һәм сәнгать чынлыгы» (1983) кебек хезмәтләрендә әлеге дәвер сүз сәнгатен өйрәнүнең методологиясен эшли, Г.Тукай, Ф.Әмирхан, Г.Исхакый, Ш.Камал һ.б. әдипләрнең иҗат портретларын тәкъдим итә. М.С. Мәһдиев исә XX йөз башы татар әдәбияты үсешенә үзгә яссылыкта якын килә, моңа кадәр киң катлам укучыга билгеле булмаган исемнәрне, аларның әдәби мирасын фәнни әйләнешкә кертеп җибәрү ягыннан зур эш башкара («Талантның социаль тамырлары: яңа революцион күтәрелеш һәм беренче империалистик сугыш еллары татар әдәбияты тарихыннан» (1990), «Әдәбият һәм чынбарлык» (1987), «Реализмга таба: XX йөз башы татар әдәбиятында чынбарлыкның чагылышы мәсьәләләре» (1989) һ.б.).

Совет әдәбияты үсеше бөтенлекле, эзлекле процесс буларак З.М. Мәҗитов, Н.Г. Юзиев хезмәтләренең үзәгенә куела. З.М. Мәҗитов совет чоры әдәбиятын укыту юнәлешендә төп белгечкә әверелә, фәнни эзләнүләрендә Бөек Ватан сугышы чоры сүз сәнгатен өйрәнүне фәнни объект итеп ала («Фатих Кәрим: Тормышы һәм иҗат юлы турында очерк», (1963), «Заман сулышын тоеп: Бүгенге әдәбият турында» (1967), «Татар поэзиясе Бөек Ватан сугышы елларында» (1989) һ.б.). Н.Г. Юзиев исә совет чоры шигъриятенең төп үсеш сукмакларын аерып билгели, поэтиканы өйрәнү юнәлешендә нәтиҗәле эш алып бара («Муса Җәлил поэмалары» (1960), «Тормыш поэзиясе» (1961), «Традицияләр яңарганда» (1966), «Сугыштан соңгы еллардагы татар совет поэзиясе» (1971) һ.б.). Әнә шулай киң карашлы, фәнни куәскә ия галимнәрнең хезмәтләрендә әдәбият тарихын өйрәнүнең бөтенлекле методикасы эшләнеп җитә. Һәр галим үзенең фәнни эшчәнлеге юнәлешендә студентларга халык авыз иҗатыннан башлап, совет чорына кадәрге сүз сәнгате тарихын укыта, үз чоры әдәби барышына бәйле фәнни казанышлары белән уртаклаша.

Кафедра эшчәнлегендәге икенче гыйльми сукмакны әдәби тәнкыйть тарихын өйрәнү тәшкил итә һәм бу эзләнүләрне 1964 елда «Татар совет әдәби тәнкыйте (1917–1932)» темасына кандидатлык диссертациясен яклаган М.С. Мәһдиев әйдәп бара. Галим татар әдәби тәнкыйте һәм публицистикасы тарихын өйрәнә, XX йөз башында дөнья күргән «Йолдыз», «Вакыт», «Аң» һ.б. вакытлы матбугат битләрен тулысынча колачлап алып тикшереп чыга, шушы юлда бик күп әдәби фактларны төгәлләштерә, татар халкының әдәби-мәдәни мирасына, фикер ияләре Г.Сәгъди, Җ.Вәлиди, Г.Гали, Г.Рәхим, Ф.Сәйфи-Казанлы, Г.Нигъмәти һ.б. фәнни мирасына багышланган мәкаләләрен бастыра. Вакытлы матбугатның милли-мәдәни, әдәби фикер үсешенә, әдәбиятны камилләштерүгә керткән өлешен раслый, милли күтәрелешне нигезләгән, шушы процессның төп идеологлары булган

шәхесләрнең эшчәнлеген өйрәнеп, татар укучысының бу чор сүз сәнгатенә, милли-мәдәни фикер үсешенә нисбәтле караш-офыкларын киңәйтә. 1967–1970 еллар аралыгында М.С. Мәһдиев «Галия» һәм «Буби» мәдрәсәләре тарихына бәйле язмалар бастыра, студентларны гына түгел, гомумән, татар укучысын, киң җәмәгатьчелекне атаклы татар мәгърифәтчеләре Гобәйдулла һәм Габдулла Бубилар, Г. Баруди, Р. Фәхретдин, Ф. Кәрими, З. Камали һ.б. эшчәнлеге белән таныштыра.

Кафедраның фәнни эшчәнлегендә теоретик эзләнүләр дә алгы планда тора. И.З. Нуруллин («Реализм турында» (1974), «Әдәбият теориясе» (1977) һ.б.), Х.Г. Госман («Шигырь төзелеше» (1975), «Әдәбият теориясе» (1980), «Тюркский стих в средние века» (1987) һ.б.) хезмәтләре теоретик юнәлештә алып барылган эзләнүләрнең нәтиҗәсе буларак дөнья күрә.

1989 елда, бер яктан, Казан университеты проректоры М.Г. Госманов тырышлыгы белән Татар филологиясе, тарихы һәм көнчыгыш телләре факультетының оешуы (2000 елда Татар филологиясе һәм тарихы факультеты итеп үзгәртелә), икенче яктан, шушы чордагы иҗтимагый-сәяси, фәлсәфи фикердәге үзгәрешләр, яңарыш татар әдәбият белеменә, гомумән, гуманитар фәннәр өлкәсенә бәйле эзләнүләргә көчле йогынты ясый. Факультетның беренче деканы итеп филология фәннәре докторы, профессор Т.Н. Галиуллин билгеләнә. Ул факультетның алга таба төп үсеш юнәлешләрен билгели һәм 2001 елга кадәр идарә итә, 2001–2011 елларда факультетта декан булып тарих фәннәре докторы, профессор И.А. Гыйләҗев эшли.

Факультет оешу дәверендә татар әдәбияты кафедрасы икегә: татар әдәбияты (мөдирләре – А.Г. Әхмәдуллин (1981–1999), Х.Й. Миңнегулов (1999–2009), Т.Ш. Гыйләҗев (2009–2011)) һәм татар телен һәм әдәбиятын укыту методикасы (мөдирләре – Т.Н. Галиуллин (1989–2008), Д.Ф. Заһидуллина (2008–2011)) кафедраларына бүленә. Әлеге бүленеш үзе үк, бер яктан, фәнни проблемаларның төгәлләшүенә, икенче яктан, гыйльми-нәзари эзләнүләрнең киңәюенә, тармаклануына этәргеч бирә. Татар әдәбиятын өйрәнү белән бәйле әлеге ике кафедра филология фәненең мөһим бер учагы, башка югары уку йортларында әдәбият укытуны координацияләү үзәге булып үсеп җитә.

Яңа структур берәмлекләрнең әдәби процессны башка концептуаль нигезгә салып өйрәнергә кирәклек мәсьәләсе күтәрелгән чорда оешып китүе бик вакытлы була. Әдәби-нәзари фикердәге яңарыш, әдәбиятны өйрәнү концепцияләренең алышынуы, төрлеләнүе әдәби тикшеренүләргә «ревизия ясый», бу үзгәрешләр татар әдәбияты кафедрасы укытучылары алдына татар әдәбияты тарихы буенча лекцияләрне яңарту, татар әдәбият белеме өлкәсендә яңа тәгълиматларга, соңгы фәнни казанышларга йөз тотып, фәнни хезмәтләр язу бурычын куя. 1995 елда факультет базасында координацион үзәк – классик университет белеме бирү буенча Укыту методик берләшмәсенең «Россия халыкларының телләре һәм әдәбиятлары» секциясе (рәисе – башта Т.Н. Галиуллин, соңрак Х.Й. Миңнегулов, сәркатибе – Ф.Ш. Нуриева) төзелү дә бу процесска уңай йогынты ясый.

Яңа, өметле яшь кадрлар белән баеган татар әдәбияты кафедрасы фольклор һәм сүз сәнгатен диахроник планда, тарихи эзлеклелектә өйрәнүне үстереп алып китә. Мисал өчен, Р.К. Ганиеваның яңа методологик казанышларга таянып алып барылган эзләнүләре сүз сәнгатен көнчыгыш Ренессансы белән бәйләнештә өйрәнүләрне тирәнәйтә. «Татарская литература: традиции, взаимосвязи» (2002), «Традиции Восточного Ренессанса в тюркских литературах Средневековья и Нового времени» (2014) кебек саллы монографияләрендә «әдәбият белеменең иң катлаулы мәсьәләләреннән саналган иҗат юнәлеше, методы турындагы фикерләр дә, шушы чор әдәбиятындагы модернистик эзләнүләр хакындагы беренчел тикшеренүләр дә, XX йөз башы татар әдәбиятына кагылышлы методологик күзәтүләр дә урын ала; әлеге дәвер сүз сәнгатенең Көнчыгыш һәм Көнбатыш әдәби традицияләрен яңа милли нигездә синтезлавы хакындагы методологик концепция дәлилләнә» [21, б. 319].

Кафедрада нәтиҗәле эшләп килгән А.Г. Әхмәдуллин («Әдәбият белеме сүзлеге» (1990), «Офыклар киңәйгәндә» (2002), «Күңелләрне уятыр: хәзерге татар драматургиясе» (2007) һ.б.) [22, б. 173–181] һәм Ә.М. Закирҗанов («Заман белән бергә: әдәби тәнкыйть мәкаләләре», 2004), А.Д. Батталова («Татар драматургиясендә йорт образының үсеш-үзгәреше (1960–2000 еллар)», 2009) әдәбият теориясе һәм татар драматургиясе мәсьәләләрен өйрәнүгә йөз тота.

М.Х. Бакиров, фәнни яңарыштан файдаланып, төрки шигырь теориясен һәм тарихын өйрәнү юнәлешендәге эзләнүләрен тирәнәйтә [23, б. 42–58], төрки-татар шигыре

төзелешенә, халык авыз иҗатына, гомумтөрки шигыренең тарихына кагылышлы монографияләрен язып («Гомумтөрки поэзиясенең яралуы һәм иң борынгы формалары» (1999), «Шигърият дөньясына сәяхәт. Фольклордан классик язма шигырьгә күчеш тарихыннан» (1999) һ.б.), студентларга белем бирә.

Х.Й. Миңнегулов һәм аның укучысы И.Г. Госманов («Мәгърифәт җырчысы», 2006) урта гасыр төрки-татар әдәбиятын, XIX гасыр сүз сәнгате үсешен өйрәнүне дәвам итә. Моннан тыш, Х.Й. Миңнегуловның фәнни эшчәнлегендәге тагын бер юнәлеш мөһаҗирлектәге татар әдипләренең иҗатын киң катлам укучыга кайтаруга бәйле үсеп китә. Хөсәен Габдүш, Сания Гыйффәт, Хәсән Хәмидулла, Әхмәд Ләбиб, Шиһаб Нигъмәти, Әхмәд Гәрәй, Гәүһәр Туганай, Минһаҗ Исмәгыйли һ.б. иҗатлары хакындагы язмалары, чит илләрдә нәшер ителгән татарча газета-журналлар турындагы хезмәтләре шул хакта сөйли («Чит илләрдәге татар әдәбияты», 2007).

Т.Ш. Гыйләҗев сүз сәнгатенең «алтын чор»ы – XX йөз башы әдәби барышын, аның үсеш-үзгәреш юлларын, әдәби юнәлешләр һәм агымнар үсешен өйрәнүне алга куя. Г.Тукай, С.Рәмиев, Дәрдемәнд, Н.Думави, Г.Ибраһимов, Ш.Камал, Г.Исхакый, Ф.Әмирхан, Г.Камал, К.Тинчурин, М.Фәйзи, Ш.Әхмәдиев, Г.Терегулов һ.б. кебек актив иҗат эшчәнлеге белән шөгыльләнгән һәр әдипнең иҗатын, әдәби-мәдәни проблемаларны Т.Ш. Гыйләҗев яңа концептуаль югарылыкта бәяләп чыга. Үзе тикшерү үзәгенә алган һәр әдипнең әдәбиятка килү юлын, әдәби карашларының эволюциясен, әсәрләрендәге дөньяга карашның, дөнья сурәтенең үсеш-үзгәрешен төрки-татар, рус-Европа әдәбиятлары фонында күзәтеп чыгып, һәркайсының әдәбият мәйданындагы урынын тәгаенләп бара, тулы иҗат портретын тергезә [24, б. 189]. 1992 елда «1920–1930 еллар татар әдәби тәнкыйте үсешендә төп тенденцияләр (метод һәм герой проблемасы)» дигән темага кандидатлык диссертациясен яклап, ул әдәби тәнкыйть тарихын өйрәнү юлында да нәтиҗәле эшли («Әдәби мирас: тарих һәм заман», 2006).

Кафедра укытучылары Р.К. Ганиева, Х.Й. Миңнегулов, Р.Ф. Харрасова, Т.Ш. Гыйләҗев Г.Исхакыйның исемен һәм әдәби мирасын кайтару юнәлешендә актив эш алып бара. Текстологик эш башкарып, аңлатмалар белән әдипнең шактый әсәрләрен киң фәнни әйләнешкә кертеп җибәрәләр, Г. Исхакый иҗатының төп чорларын аерып чыгарып, бөтенлекле фәнни бәя бирәләр.

Яңарыш җилләре татар әдәбиятыннан программа һәм дәреслекләрне яңартуны, эчтәлеген тулысынча үзгәртүне таләп итә. А.Г. Әхмәдуллин җитәкчелегендә Казан дәүләт педагогия университеты (хәзерге вакытта Казан федераль университеты) галимнәре белән берлектә эшче коллектив төзелеп, программа һәм дәреслекләр, методик кулланмалар язу эше башлана. Бу эшкә Х.Й. Миңнегулов, Ш.Ә. Садретдинов, Ә.М. Закирҗановлар да актив катнашып китеп, 2011 елга кадәр татар мәктәпләре шушы коллектив төзегән дәреслекләр аша татар әдәбиятын үзләштерә, сүз сәнгатенең иң гүзәл ядкярләре белән таныша.

1989 елда гына оешып, төрле буын һәм юнәлеш авторларын берләштергән Татар телен һәм әдәбиятын укыту методикасы кафедрасының фәнни эшчәнлеге «Татар телен һәм әдәбиятын мәктәптә һәм югары уку йортында укытуның методологиясе һәм методикасы» проблематикасы тирәсенә берләшә. Кафедрадагы әдәбиятчыларның бер өлеше XX гасыр һәм XX-XXI гасыр сүз сәнгате үсешен, нәзари фикер үсешен (җитәкчесе – Т.Н. Галиуллин) өйрәнүгә йөз тотса, бер өлеше методик аспектта эзләнүләр (җитәкчесе – Д.Ф. Заһидуллина) алып бара.

Д.Ф. Заһидуллина, А.Г. Яхин һәм Ф.Х. Җәүһәрова урта мәктәптә әдәбият укыту проблемаларын өйрәнүне тирәнәйтә. Д.Ф. Заһидуллина әдәбият укыту методикасыннан бүген дә актив кулланылышта булган дәреслекләр яза («Урта мәктәптә татар әдәбиятын укыту методикасы» (2000), «Мәктәптә татар әдәбиятын укыту методикасы» (2004) һ.б.). А.Г. Яхин 1991 елдан урта мәктәпнең 1–11 сыйныфлары өчен әдәби әсәрне һәм сүз сәнгатен структур-семиотик методка таянып үзләштерүгә, укучының мөстәкыйль мантыйкый фикерләвен үстерүгә, «гадидән катлаулыга принцибы аша әдәби әсәрдән әдип иҗатын, аннан әдәби чорны һәм әдәби барышны анализлауга» [25, б. 171] йөз тоткан альтернатив программа, дәреслекләр һәм методик әсбаплар әзерләү эшенә керешә, аларны университет һәм Питрәч районының Шәле урта мәктәбе базаларында апробацияли, шул рәвешле дәреслекләрне камилләштерә һәм республика мәктәпләренә тәкъдим итә. Нәтиҗәдә, методик планда ике кафедра урта гомуми мәктәпләр өчен татар әдәбиятыннан

ике юнәлештәге – традицион һәм альтернатив – авторлык программалары һәм дәреслекләр линиясе эшләп өлгертә! ФДББС шартларында татар әдәбиятын укыту программалары эшләүне соңрак Д.Ф. Заһидуллина һәм Н.М. Йосыпова дәвам итә («Татар телендә белем бирүче мәгариф оешмалары өчен татар әдәбиятыннан үрнәк программа», 2011). Алар авторлыгындагы программа 2023 елга кадәр татар мәктәпләре өчен төп уку-укыту программасы буларак хезмәт итә.

Моннан тыш, кафедра укытучылары Д.Ф. Заһидуллина, Ф.Х. Җәүһәрова, Н.М. Йосыпова, Г.Р. Гайнуллина, А.Д. Батталова методик кулланмалар, әсбаплар, югары уку йортлары өчен дәреслекләр эшләүне активлаштыра, филология факультеты укытучылары белән берлектә (В.Р.Әминева, М.И. Ибраһимов, А.З. Хәбибуллина, Э.Ф. Ногъманова) белән берлектә компаративистик эзләнүләрне көчәйтә: «Татар әдәбияты: теория, тарих» (Д.Ф. Заһидуллина, Ә.М. Закирҗанов, Т.Ш. Гыйләҗев, Н.М. Йосыпова, 2004, 2006), «Әдәби әсәр: өйрәнәбез һәм анализ ясыйбыз» (Д.Ф. Заһидуллина, В.Р. Әминева, М.И. Ибраһимов, 2007), «Әдәбият белеме: терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге» (Д.Ф. Заһидуллина, Ә.М. Закирҗанов, Н.М. Йосыпова, В.Р. Әминева, М.И. Ибраһимов, Т.Ш. Гыйләҗев, Г.Р. Гайнуллина, 2007), «Татар әдәбиятыннан таблицалар» (Д.Ф. Заһидуллина, Н.М. Йосыпова, Ә.М. Закирҗанов, 2009), «Татар әдәбияты. Бердәм республика имтиханына әзерләнү өчен кулланма» (Н.М. Йосыпова, 2008, 2010, 2011), «XX гасыр татар әдәбияты тарихы: югары уку йортлары өчен дәреслек» (Д.Ф. Заһидуллина, Н.М. Йосыпова, 2011), «Фольклор практикасы» (Ф.Х. Җәүһәрова, А.Д. Батталова, 2009) һ.б.

Т.Н. Галиуллин XX гасыр татар поэзиясен әдәби барыш буларак диахроник аспектта өйрәнә, шушы юлда үз мәктәбен булдырып, эшен дәвам итәрлек шәкертләрне әзерли («Шигърият баскычлары» (2002), «Шәхесне гасырлар тудыра» (2003), «Әдәбият – хәтер хәзинәсе» (2008), «Яктылык» (2011) һ.б.) Д.Ф. Заһидуллина милли әдәбият тарихын синхрон система буларак тикшереп, үз фәнни концепциясен тәкъдим итә, аның фәнни эзләнүләре дә, нигездә, шуңа карый («Әдәбият кануннары һәм заман» (2000), «Модернизм һәм XX йөз башы татар прозасы» (2003), «Дөнья сурәте үзгәрү» (2006), «Яңа дулкында» (2006), «История науки о литературе у татар» (2011) һ.б.). Н.М. Йосыпова һәм Г.Р. Гайнуллинаның фәнни эшчәнлеге XX йөз һәм хәзерге татар әдәбиятын өйрәнүгә йөз тота, аларның хезмәтләрендә сүз сәнгатенең эчтәлек һәм форма үзенчәлекләре структур-семиотик һәм нарратологик аспектта бәяләнә, стильләр, иҗади агымнар һәм юнәлешләр аспектында яңа тенденцияләр формалашуы тикшерелә.

Ә моның кадәр киң колачлы фәнни-методик эшчәнлек алып бару өчен өчен яңа көчләр, киң карашлы, теге яки бу әдәби күренешкә үз анык мөнәсәбәте булган яшь галимнәрнең кирәклеге бәхәссез. 1991 елда ачылган Россия Федерациясе халыклары әдәбияты, төрки телләр буенча докторлык һәм кандидатлык диссертацияләрен яклау Советы (рәисе – Т.Н. Галиуллин) оешуның әһәмияте бу яктан бәһаләп бетергесез була. Шул чордан башлап, бүгенгә кадәр татар әдәбияты кафедрасы мөгаллимнәренең күбесе, шушы ук уку йортында укытучы өлкән буын галимнәр җитәкчелегендә кандидатлык, докторлык диссертацияләрен өлгертеп, әлеге Совет аша гыйльми дәрәҗә ала, галим булып өлгерә (Ф.Г. Галимуллин, Х.Й. Миңнегулов, М.Х. Бакиров, Д.Ф. Заһидуллина, Ф.С. Сәйфуллина, Ә.М. Закирҗанов, Н.М. Йосыпова, Г.Р. Гайнуллина, А.Д. Батталова, И.Г. Гомәров, Л.И. Хәйдәров, Р.Р. Сабиров һ.б.). Бу үзе үк Казан университетында татар әдәбият белеменең тулы бер фәнни мәктәп булып формалашып, оешып җитүе хакында сөйли.

2011 елдан татар әдәбияты кафедрасы өчен яңа чор башлана: Казан федераль университеты оешу, Казан дәүләт университетында һәм Татар дәүләт гуманитар-педагогика университетында яшәп килгән татар әдәбиятын өйрәнү белән шөгыльләнүче кафедраларның кушылуы сыйфат һәм сан үзгәрешләренә китерә. Һәр ике якның үз яңалыклары белән берләшүе фәнни һәм методик тикшеренүләрне киңәйтеп һәм тирәнәйтеп җибәрә, уку йортының федераль университет дәрәҗәсенә күтәрелүе фәнни эзләнүләрне яңа яссылыкларда алып бару мөмкинлеген бирә.

Бүгенге көндә татар әдәбияты кафедрасы (мөдире – Ф.С. Сәйфуллина) укытучыларының фәнни эшчәнлеге татар әдәби барышын көнбатыш һәм көнчыгыш мәдәниятләре синтезында, Идел буе һәм Урал алды халыклары сүз сәнгате контекстында комплекслы тикшерү кысаларында алып барыла. Ф.С. Сәйфуллина, Л.И. Минһаҗева, Г.Ф. Каюмоваларның күпсанлы хезмәтләрендә

татар балалар әдәбиятының, регион әдәбиятының һәм халык авыз иҗатының әдәби-эстетик һәм фәлсәфи-этик нигезләре фәнни өйрәнү объектына әверелә, Идел буе һәм Урал алды халыклары сүз сәнгате белән чагыштырма планда тикшерелә. Ф.Г. Галимуллин, Н.М. Йосыпова, М.М. Хәбетдинова, Г.Р. Гайнуллина, Т.Ш. Гыйләҗев татар әдәбиятын рус, көнбатыш һәм көнчыгыш мәдәниятләре синтезында, Идел буе һәм Урал алды халыклары сүз сәнгате контекстында диахроник һәм синхроник аспектларда өйрәнү белән шөгыльләнә, аларның хезмәтләре сүз сәнгатенең, татар әдәби тәнкыйтенең теориясен, тарихын бөтенлекле система буларак бәяләүгә йөз тота. Шушы эзләнүләрнең нәтиҗәсе буларак, ел саен кафедра укытучыларынң монографияләре, уку-укыту әсбаплары, югары уку йортлары өчен татар әдәбиятыннан дәреслекләре дөнья күрә.

Шушы вакыт аралыгында кафедрада 2 докторлык диссертациясе яклана (Н.М. Йосыпова, Л.И. Минһаҗева), кафедра укытучылары җитәкчелегендә (Ф.Г. Галимуллин, Ф.С. Сәйфуллина, Л.И. Минһаҗева, Н.М. Йосыпова, Г.Р. Гайнуллина) дистәдән артык укучы аспирантура үтеп, кандидатлык һәм докторлык диссертацияләрен яклый. Идел буендагы һәм чит илләрдәге төрки халыклар әдәбиятын өйрәнү белән шөгыльләнүче галимнәр татар әдәбияты кафедрасында стажировка үтеп, белемнәрен күтәрә, уртак проектлар башкара.

Кафедра укытучылары академик басмалар, энциклопедияләр төзүдә актив катнаша, аерым әдипләрнең иҗатын системалы өйрәнү, рухи мирасны татар укучысына кайтару, киң фәнни әйләнешкә кертү юнәлешендә актив эшчәнлек алып бара (Ф.С. Сәйфуллина, М.М. Хәбетдинова, Г.Р. Гайнуллина, Н.М. Йосыпова), гомуми урта белем бирү мәктәпләре һәм гимназияләре өчен дәреслекләр, методик кулланмалар, уку-укыту әсбаплары төзү эшенә җәлеп ителә (Ф.Г. Галимуллин, Л.И. Минһаҗева, Н.М. Йосыпова).

Кафедрада татар әдәбиятын өйрәнү белән бәйле бик күп проектлар тормышка ашырыла. Моннан тыш, югары уку йортларында татар әдәбиятын өйрәнү юнәлешендәге бердәнбер мөстәкыйль структур берәмлек буларак, кафедра укытучылары республикабызның әдәби-мәдәни, иҗтимагый тормышында актив катнаша. Бүгенге көндә татар әдәбияты кафедрасы – гади кафедра гына түгел, татар әдәбиятын өйрәнү, аны яшьләргә пропагандалау, шушы юнәлештәге фәнни һәм методик эзләнүләрне координацияләү үзәге дә.

**Төп нәтиҗәләр**

2024 нче елда Казан университетының татар әдәбияты кафедрасы үзенең 80 еллык юбилеен билгеләп үтә, уку йортында татар әдәбият белеме белән бәйле эзләнүләрнең башланып, киң колач алып китүенә дә 80 ел тула. Үзенең юл башын кечкенә генә берәмлектән башлаган кафедра бу түгәрәк датаны татар әдәбиятын өйрәнүнең фәнни учагы һәм фәнни-методик эзләнүләрне координацияләү үзәге дәрәҗәсенә күтәрелеп каршылый. Шушы вакыт эчендә кафедрада татар әдәбият белеме өлкәсендәге эзләнүләр, нигездә, өч аспектта – теоретик, диахроник һәм синхроник, методик юнәлешләрдә алып барыла. Әлеге гыйльми-методик эзләнүләр студентларга белем бирү өчен монографияләр, уку-укыту кулланмалары, лекцияләр, махсус курс программалары белән ныгытыла һәм эзлекле, бөтенлекле, тотрыклы система буларак оешып җитә. Төрле елларда университетта укып, татар әдәбияты кафедралары укытучылары тарафыннан ук әзерләнгән галимнәр буыны үсеп җитеп, инде бүген үзләре студентларга белем бирә, шәкертләрен әзерли, фәндә үз сүзен әйтеп, буыннар бәйләнешен тәэмин итә. Казан университетындагы бу юлыбыз алга таба да дәвамлы һәм бәрәкәтле булсын иде!

**Әдәбият**


1. Замалетдинов Р.Р., Хабутдинова М.М. История создания отделения татарского языка и литературы в Казанском университете в воспоминаниях преподавателей и первых студентов // Татарика. 2018. №1(10). С. 91–113.
2. Тумашева Д.Г. Развитие татарского языкознания в Казанском университете (1944–1995) // Гасырлар авазы – Эхо веков. 1996. №1/2. С. 212–216.
3. Миннегулов Х.Ю. Татарская словесность в Казанском университете // Научный Татарстан. 2015. № 1. С. 65–71.
4. Ханипова И.И. Создание кафедры татарского языка и литературы в Казанском государственном университете и ее деятельность с середины 1940-х – 1950-е годы // Историческая этнология. 2021. Т. 6. № 2. С. 231–241.
5. Ярмакеев И.Э., Мухаметшина Р.Ф. Филология в Казанском федеральном университете: прошлое – настоящее – будущее // Мир русского слова. 2021. № 1. С. 111–121.
6. Миннегулов Х.Ю. Хатип Усманович Усманов. Казань: Казанский университет, 2002. 20 с.

7. Галиуллин Т.Н. Нил Гафур улы Юзиев. Казан: Казан университеты, 2002. 20 б.

8. Миңнегулов Х.Й. Шәйхи Әләветдин улы Садретдинов. Казан: Казан университеты, 2003. 20 б.

9. Заһидуллина Д.Ф. Мөхәммәт Сөнгат улы Мәһдиев. Казан: Казан университеты, 2003. 28 б.

10. Татар факультетына 50 ел. Казан: Шәкли фәхем, 1994. 70 б.

11. Татар факультетына 60 ел. Казан: Казан ун-ты типографиясе, 2004. 143 б.

12. Татар филологиясе һәм тарихы факультеты. Казан: Б. и., 2004. 42 б.

13. Татарстан Республикасы Дәүләт архивы. Ф. Р-1337. Оп. 2. Д. 167. Б. 1–51.

14. Татарстан Республикасы Дәүләт архивы. Ф. Р-1337. Оп. 2. Д. 168. Б. 5–145.

15. Татарстан Республикасы Дәүләт архивы. Ф. Р-1337. Оп. 2. Д. 507. Б. 9–20.

16. Татарстан Республикасы Дәүләт архивы. Ф. Р-1337. Оп. 2. Д. 238. Б. 8.

17. Юсупова Н.М. Научно-критическая деятельность Нила Гафуровича Юзиева // TATARICA. 2021. № 16. С. 172–178.

18. Закирзянов А.М. Вкладывая тепло своей души (К 90-летию Резеды Ганиевой) // Tatarica. 2022. №1 (22). 155–163 б.

19. Мотигуллина А.Р., Гайнуллина Г.Р. А. Яхин как яркий представитель научной школы системно-комплексного изучения литературы и искусства Казанского университета // Филология и культура. Philology and Culture. 2016. № 4 (46). С. 314–324.

20. Харрасова Р.Ф. Ибраһим Зиннәт улы Нуруллин – галим, тәнкыйтьче һәм прозаик // Tatarica. 2023. №20 (1). С. 182–188.

21. Юсупова Н.М., Гайнуллина Г.Р. Жизнь, посвященная науке (К 90-летию со дня рождения профессора Казанского университета Р. К. Ганиевой) // Филология и культура. Philology and Cultura. 2022. №3 (69). С. 316–321.

22. Сайфулина Ф.С. Күренекле әдәбият галиме Азат Гыйльмулла улы Әхмәдуллин// Tatarica. 2022. №2(19). С. 173–181.

23. Йылмаз Г.М., Завгарова Ф.Х., Хабутдинова М.М. Творческий портрет фольклориста Марселя Бакирова в зеркале его личных воспоминаний и в оценке современников // Tatarica. 2023. №2 (21). С. 42–58.

24. Хабутдинова М.М., Юсупова Н.М. Литературно-критическая и научная деятельность Т.Ш. Гилазова // Филология и культура. Philology and Culture. 2020. №4(62). С. 187–190.

25. Юсупов А.Ф. Альберт Гатуф улы Яхинның фәнни-методик эшчәнлеге // TATARICA. 2021. № 17 (1). Б. 166–171.

---

# ТАТАРСКОЕ ЛИТЕРАТУРОВЕДЕНИЕ В КАЗАНСКОМ УНИВЕРСИТЕТЕ: ИСТОРИЯ И СОВРЕМЕННОЕ СОСТОЯНИЕ

**Нурфия Марсовна Юсупова**,
Казанский федеральный университет,
Россия, 420008, г. Казань, ул. Кремлевская, д. 18,
faikovich@mail.ru.

В статье рассматривается формирование и развитие татарского литературоведения в Казанском университете в контексте общероссийского литературоведения, систематизированы сведения о вкладе ученых в татарское литературоведение. Казанский университет имеет более 80-летнюю историю всестороннего изучения татарской литературы. Татарская литературоведческая школа начала складываться еще с 1944 г., фактически с первых лет существования нового отделения – отделения татарского языка и литературы в Казанском университете. У истоков школы стояли выдающиеся ученые Казанского университета. Высокая эрудированность, применение новых методов в изучении татарской литературы, широкая проблематика исследований определили значительный вклад многих из них в историю науки о литературе. В статье охарактеризованы основные научные школы, история их становления и вклад отдельных ученых в разработку ключевых проблем истории татарской литературы, теории литературы и методики преподавания. Хронологические рамки исследования охватывают период с 1944 по 2024 г. В ходе исследования обобщается деятельность кафедры татарской литературы на современном этапе.

**Ключевые слова**: Казанский университет, татарская литература, теория литературы, научная деятельность, кафедра татарской литературы